ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «физкультура, спорт, реабилитация һәм гражданнарның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә бәйле рәвештә башка чаралар үткәрү» сүзләрен «физкультура, спорт, реабилитация, абилитация чаралары һәм гражданнарның физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүләренә бәйле рәвештә башка чаралар үткәрү» сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяда:
а) исемдә «физик реабилитацияләү» сүзләреннән соң «һәм абилитацияләү» сүзләрен өстәргә;
б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Инвалидларны һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларны кеше организмының бозылган йә булмаган функцияләрен һәм инвалидларның һәм

сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның көнкүреш, иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеккә сәләтләрен спорттан файдаланып торгызуга яисә булдыруга юнәлдерелгән чаралар (шул исәптән физкультура-савыктыру чаралары) һәм хезмәтләр күрсәтү комплексын, адаптив физик культура һәм адаптив спорт чараларын һәм ысулларын кулланып физик реабилитацияләү һәм абилитацияләү һәм инвалидларны социаль адаптацияләү реабилитацияләү оешмаларында, инвалидларның физкультура-спорт клубларында, физкультура-спорт оешмаларында һәм инвалидларны комплекслы реабилитацияләү һәм абилитацияләү системасының дәүләтнеке булмаган оешмаларында гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 өлештә «физик реабилитацияләүнең» сүзләреннән соң «һәм абилитацияләүнең» сүзләрен өстәргә;

г) 3 өлештә «физик реабилитацияләүгә» сүзләреннән соң «һәм абилитацияләүгә» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 92 (I өлеш), «медицина,» сүзен «реабилитация, медицина ярдәме» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 25 декабрь
№ 107-ТРЗ